**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУРАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӨРӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел , 28 нче февраль Мөрәле ав. № 2

Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Башкарма комитетының «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм өч һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге бюджетыннан субсидия бирү тәртибе турында» 2021елнын 11 октябрендәге 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 1662 номерлы карары нигезендә Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл жирлеге Башкарма комитетының «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм өч һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге бюджетыннан субсидия бирү тәртибе турында» 2021елның 11 октябрендәге 9 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 бүлекнең исемендә «контроль» сүзен «контроль (мониторинг)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Р.Зиннәтуллин